Scientific Chronicles of the Turkic World

Төрки дөнья фәнни хроникасы

Научная хроника тюркского мира

# LATEST EVENTS IN 2015

On September 17-19, Tatarstan Academy of Sciences and Kazan Federal University hosted the 3rd International Conference on Computer Processing of Turkic Languages, TurkLang'2015.

The traditional scientific areas of the conference are formal models for Turkic languages, national localization of computer systems and terminology, electronic corpora of Turkic languages, systems of morphological and syntactical processing of texts, systems of speech recognition and synthesis, semantic text processing, machine translation systems, intelligent systems and technologies for learning Turkic languages, and linguistic ontologies in Turkic languages.

In their reports, the speakers noted the relevance of interdisciplinary research in the sphere of computer processing of Turkic languages and the importance of such activities for the preservation and development of the culture of Turkic peoples.

On September 18-19, the conference was held at Leo Tolstoy Institute of Philology and Intercultural Communication, Kazan Federal University. In addition to plenary and section reports, it held various workshops and round table discussions, presentations of software systems, virtual sessions with the participation of foreign speakers.

In addition to the representatives of the Academia, the conference was attended by the representatives of the business community, in particular, the employees of Yandex company: they made a presentation on the system of the Tatar-Russian machine translation.

The participants of the conference agreed to develop cooperation and to combine efforts in the study of a wide range of issues and challenges, the successful solution of which requires the combination of the results of linguistic research and modern computer methods for processing linguistic data.

---

On October 2, 2015, the Institute of Asian and African Studies of Lomonosov Moscow State University (MSU) hosted the 23rd International Conference on the Turkic Languages Studies, "Dmitriev Readings", held in honour of the anniversary of Professor Dmitry Mikhailovich Nasilov, head of the Department of Turkic Philology of the Institute of Asian and African Studies (IAAS) at MSU, Doctor of Philology. His scientific works on Turkic and Altaic linguistics (the history of Turkic studies, research on comparative and historical, theoretical and descriptive grammar of Turkic languages and Altai linguistics, etc.) are widely known both in this country and abroad as well as his contributions to the preparation of more than one generation of turkologists and altaicists. In addition to heading the department and teaching in the IAAS, Dmitry Mikhailovich performs a huge social work: he is the Deputy Chairman of the

Russian Turkic Studies Committee at the Department of Historical and Philological Studies of RAS, the editor-in-chief of the “Russian Turkology” journal, a member of the expert group on languages of indigenous peoples of the Russian Federation at the Committee on Issues of Nationalities Affairs of the Russian Federation State Duma, an expert of Russian Foundation for Humanities, an honorary member of the Turkish Language Association (Türk Dili Kurumu).

The scientists from universities and research institutes from Moscow, St.Petersburg, Kazan, Kyzyl, Elista, Kiev, Ankara, and other cities presented 34 reports within two thematic sections of the conference. The Department of Turkic Philology of IAAS MSU was the main organizer of the event aimed at strengthening scientific ties in the Turkic World and preserving the traditions of Moscow Turkological School.

---

On October 12-15, 2015, Leo Tolstoy Institute of Philology and Intercultural Communication, Kazan Federal University (KFU) held the International Conference “I.A.Boduen de Courtenay and World Linguistics”, dedicated to the 170$^{th}$ anniversary of Ivan Aleksandrovich Baudouin de Courtenay (1845-1929), the founder and the head of the world-famous Kazan linguistic school, a member of the Academy of Sciences, an honorary professor of the University of Kazan and the 140$^{th}$ anniversary of his work in Kazan University.

The conference was attended by scholars from Austria, Germany, Poland, Turkey, the Czech Republic, the CIS countries and from different cities of Russia.

At the plenary session, the guests and the participants of the conference were welcomed by KFU Vice-Rector for scientific work, Doctor of Geology, Professor D.K.Nurgaliev, Deputy Minister of Education and Science of the Republic of Tatarstan I.R.Mukhametov, Director of the Institute of Linguistics, Doctor of Philology, Professor V.M.Alpatov, Deputy Ambassador of Poland to Russia M.Cheslik.

The co-organizers of the conference were the Institute for Linguistic Studies of the Russian Academy of Sciences, the Russian Language Institute of the Russian Academy of Sciences, the Institute of Linguistics of the Russian Academy of Sciences, Giessen Centre “Eastern Europe”, the Embassy of the Republic of Poland in the Russian Federation.

The international conference was devoted to a wide range of issues and trends in contemporary theoretical and applied linguistics, which were either initiated or developed by I.A.Boduen de Courtenay and other representatives of the Kazan linguistic school.

At present, the ideas of the Kazan linguistic school (KLS) are actively implemented by the philologists of Kazan University. It is essential to note that the fundamental ideas of the KLS have not been lost over more than a century and their development has always been consistent with the modern scientific paradigms.

This was noted in the reports of the leading scholars of Russia and foreign countries, who spoke at the plenary session: Professor V.M.Alpatov, Doctor of Philology, Director of the Institute of Linguistics of the Russian Academy of Sciences; Professor T.V.Ahutina, Doctor of Psychological Sciences, Head of the Laboratory of Neuropsychology of Moscow State University; Professor R.R.Zamaletdinov, Doctor of Philology, Director of Leo Tolstoy Institute of Philology and Intercultural Communication; Professor E.V.Golovko, Doctor of Philology, Deputy Director of the Institute for Linguistic Studies of the Russian Academy of Sciences; A.Kiklevich, Doctor of Philology, Professor of the University of Warmia and Mazury in Olsztyn; and H.Miklas, Doctor of Philology, Professor of the University of Vienna.

The sessions discussed the current issues of the development of the ideas suggested by the Kazan linguistic school: in the sphere of applied linguistics – computational linguistics, neurolinguistics, psycholinguistics and achievements in the sphere of cognitive linguistics, issues of phonetics, phonology, morphemics, word formation, grammar, text and discourse, and semantics.

The conference was organized with the support of the Ministry of Education and Science of the Russian Federation and the Republic of Tatarstan, the Cabinet of Ministers of the Republic of Tatarstan, the State Program of the Republic of Tatarstan “The preservation, study and development of the state languages of the Republic of Tatarstan and other languages in the Republic of Tatarstan from 2014 to 2020”.

---

The 4th International Forum "Preservation and Development of Languages and Cultures" was opened in Kazan Federal University on October 14, 2015.

The forum was attended by more than 500 scholars from Russia and the CIS and foreign countries: the USA, Germany, England, Austria, Turkey, Ukraine, Iran, Armenia, Kazakhstan, Uzbekistan and other countries.

The issues of the preservation and development of languages and cultures are relevant for almost all enlightened people. According to UNESCO, half of the 6.5 thousand languages in the world are endangered. Experts believe that if more than one third of children or other people do not learn their native languages, they may disappear.

The forum was prepared by Kazan Federal University under the auspices of the Cabinet of Ministers of the Republic of Tatarstan, the Ministry of Education and Science of the Republic of Tatarstan, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, the Federal national-cultural autonomy of Tatars, the Executive Committee of World Congress of Tatars, the Inter-University Council on the development of multicultural education at the Council of Rectors of the Republic of Tatarstan, the Education and Methodological Commission in "Native (Tatar) language and literature" of Educational and Methodical Association on Education in the sphere of teacher training at Moscow State Pedagogical University, the Council on Philology of Education and the Methodological Association on Classical University Education at Lomonosov Moscow State University.

At the opening ceremony of the forum, the guests and the participants were greeted by KFU Vice-rector for educational activities D.Tayursky, Director of Leo Tolstoy Institute of Philology and Intercultural Communication R.Zamaletdinov, Head of the Department on national policy of the Department of President of the Republic of Tatarstan on domestic policy D.Mustafin, Head of Division of Culture and Tatarstan Peoples' Languages Development of the Cabinet of Ministers of the Republic of Tatarstan G.Gilmanov, the Consul General of the Republic of Turkey in Kazan and others.

The following events took place within the forum:

International Scientific and Practical Conference "The Preservation and Development of Languages and Cultures in a Multicultural and Multi-confessional Society: the International Experience and Modern Technologies";

International Scientific Conference "Contemporary Germanic Studies";

International Scientific and Practical Conference "Literature and Art Culture of the Turkic Peoples in the East–West Context";

The 2nd International Scientific and Practical Conference "Current Aspects of Applied Comparative Linguistics: Teaching a Foreign Language with the Native Language Support";

Republican interuniversity scientific and methodical seminar of the Tatar language teachers "The Use of Modern Methods in Teaching the Tatar Language to Students of Non-linguistic Faculties";

All-Russian Scientific and Practical Conference of pupils and students "Magdeev Readings";

The 4th International Scientific and Practical Conference "Art and Art Education in the Context of Cross-cultural Interaction";

The 8th Republican Interuniversity Competition in the Tatar language (for Russian-speaking students).

---

On October 15-17, 2015, the academic staff of the Division of Tatar Philology and Culture named after G.Tukay at Kazan (Volga region) Federal University (KFU), represented by Ense Hanafievna Kadirova and Zoya Nikolaevna Kirillova, participated in the International Symposium "The 8th Dünya Dili Türkçe", which took place in Canakkale Onsekiz Mart University, Turkey.

Linguists from around the world arrived at this symposium, dedicated to Turkic languages. In addition to experts from various cities in Turkey, there were delegations and individual scholars from such countries and republics as Russia, Azerbaijan, Kazakhstan, Uzbekistan, Kyrgyzstan, Ukraine, Bulgaria, Macedonia, Albania, Bosnia and Herzegovina and Afghanistan. In addition to scholars from KFU, Tatarstan was represented by well-known dialectologist Ferits Yusupov, and folklorist Leila Davletshina.

Ense Kadirova, Associate Professor in the Department of Tatar Linguistics, made a presentation on the "Turkish-Arabic Dictionary", which was printed in 1581 and is now kept in the Lobachevsky Scientific Library in Kazan. She spoke about basic topic groups, features of the writing and the translation of lexical units, and presented photocopies of certain pages from the Dictionary. Zoya Kirillova, Associate Professor in the Department of General and Turkic Linguistics, acquainted the audience with the words of Turkish origin, which are in the dialects of the baptized Tatars, but are not used in the modern Tatar literary language. She spoke about words borrowed from the Russian, Arabic, Persian, Udmurt and Chuvash languages, provided numerous examples, and presented photographs and samples of clothing similar to that of the Udmurts and Chuvashes. The symposium participants listened to the speeches with great interest, asked questions and expressed their opinions.

The International Symposium "Dünya Dili Türkçe" is held annually in different cities of Turkey. This year the choice fell on the city of Canakkale, and it was not accidental. We know from history that 100 years ago, this city fought a battle of World War I which was crucial for Turkey. The countries of the Entente wanted to capture the Dardanelles, but as a result of the bloody fighting, Turkish troops managed to win and retain their land. The university which hosted the symposium was named in honour of the famous events of March 18, 1915.

This year again, the Turkological symposium, which unites Turkic peoples and studies their linguistic features and common historical roots, has achieved its goal. The participants will remember the city of Canakkale, the pride of the Turkish people, which is located in the Dardanelles and connects the Marmara and the Aegean Seas, for its surprisingly beautiful nature and hospitable people.

---

On October 16-18, the 2nd Congress of the International Association of Tatars at the EU "European Alliance of Tatars" was held in Paris. The venue of the congress was the Russian Embassy in France.

It was attended by Alexander Orlov, Extraordinary and Plenipotentiary Ambassador of the Russian Federation in France, Igor Shpynov, a representative of Russian Cooperation in France, and Konstantin Klimovsky, Director of the Russian Center of Science and Culture in Paris, Deputy Director of the Department for relations with Compatriots Living Abroad at the Ministry of Foreign Affairs of the Russian Federation.

By the order of the President of the Republic of Tatarstan Rustam Minnikhanov the Republic of Tatarstan was represented by Ravil Akhmetshin, Deputy Prime Minister of the Republic of Tatarstan, Plenipotentiary of the Republic of Tatarstan in the Russian Federation.

At the event, the Republic of Tatarstan was also attended by Razil Valeev, a deputy of the State Council of Tatarstan, Chairman of the Committee for Culture, Science, Education and National Issues, Rinat Zakirov, a deputy of the State Council of Tatarstan, Chairman of the Executive Committee of the World Congress of Tatars, Iskander Yusupov, Plenipotentiary of the Republic of Tatarstan in France. Ravil Akhmetshin welcomed the participants of the Congress and conveyed good wishes on behalf of President of Tatarstan Rustam Minnikhanov. He noted the importance of such meetings for the consolidation of fellow countrymen abroad in order to preserve the native language and national traditions.

The congress was attended by the representatives of the Tatar organizations from Belgium, Bulgaria, Germany, Lithuania, France, Czech Republic, Sweden and other countries. Many of them made presentations on the issues of concern. The participants spoke about the role of the mother tongue in the preservation of cultural identity, the necessity of cooperation with Tatarstan, and the cooperation of Tatar organizations with local authorities in the their countries of residence.

Also, a documentary film "*Voyna neproshennykh*" ('The War of the Unforgiven') was demonstrated as a part of the Congress. The film shows the events which happened during the Second World War. The film is a large-scale study of the difficult fate of the Volga-Tatar Legion members within the Wehrmacht "Idel-Ural", which consisted of prisoners of war who were Tatars, Bashkirs, Mari, Chuvash and Udmurt peoples, and Mordovians.

The Alliance of Tatars of Europe was organized in Brussels in the European Parliament by the union called "Tatars in Belgium". Over more than two years the Tatar movement in Europe has developed. By

the time the Second Congress was held, the activists from twenty European countries had achieved noticeable results: the Tatar language learning in Sunday schools had become more efficient, additional online classes had been arranged, more people had registered in on the online school "Ana tele".

---

On October 23-24, 2015, the International Kazakh-Turkish University named after Khoja Ahmed Yassawi (Turkestan) hosted the 6th International Congress of Turkologists. The proceedings were attended by the scientists from Turkey, Azerbaijan, Kazakhstan, Uzbekistan, Kyrgyzstan, Russia, the United States and other countries. The main item on the agenda of the Congress concerned the issues of translation in the history of Turkic languages, i.e. translations between Turkic and non-Turkic languages. In addition, congress participants discussed various aspects of linguistics, literary studies, history and culture.

Professor Hatip Minnegulov of Kazan Federal University made a welcome speech at the plenary session. He made reports "On Translations of Kazakh Literature into the Tatar Language" and "Professor B. Kenzhebaev and Tatar Literature in the Early Twentieth Century" and took part in the discussions. Kazan professor gave the magazines *Tatarica*, *Kazan utlary, Bezneң miras* and other publications as a gift to the University library as well as a collection of poems by Kazakh poets Nurlan Orazalin and Galim Zhaylybay translated by Robert Minnullin and Rafis Kurban. During his stay in Kazakhstan, Pr. Minnegulov appeared more than once on television of the brotherly country.

---

On October 26-28, 2015, St. Petersburg State University hosted the International Scientific Conference "Language and Literature of the Turkic Peoples" dedicated to the 180th anniversary of the Turkish Philology Department. The purpose of this conference was to summarize research on Turkic philology and to define new approaches and current research issues. It was attended by beginning researchers and outstanding scientists representing foreign and Russian Turkology. At the gala meeting, the participants spoke about the history and development of the department and outlined new trends of world and Russian Turkology. N.N.Telitsin, Associate Professor, Dean of the Department of Turkic Philology of the Faculty of Oriental Studies at St.Petersburg State University, told the audience about the current state and prospects of the department. The meeting also noted the special role of Kazan University in the formation of the department. R.M.Valeev, Doctor of History, professor of Kazan Federal University, made a welcoming speech on behalf of the turkologists from the Republic of Tatarstan. He spoke about the famous turkologists of the past, who were a connecting link between the universities. The conference covered the following issues: the study of Turkic ancient and medieval monuments, the languages and the current state of folklore and literature of the Turkic peoples. "XXX Kononov Memorial Lectures" were held at the University within the framework of the conference and the exhibition "Literature and Culture of Turkey" was organized in the new building of the National Library by the Russian National Library together with the Department of Turkic Philology of the Faculty of Oriental Studies at St. Petersburg State University, the Russian-Turkish Cultural Center and the Association for International Cooperation. The exhibition displayed the publications from the funds of the Russian National Library telling about literature, art and culture of Turkey, from the era of ancient civilizations to the present day. Much of the exhibition was devoted to the literature of the Middle Ages, Modern and Contemporary Times. An important part of the exhibition was the works of the teaching staff of the Turkic Philology Department, the Faculty of Oriental Studies at St. Petersburg State University.

---

On October 27, 2015, a seven-volume academic edition of *Istoriya tatar s drevneyshikh vremen* ('The History of the Tatars since Ancient Times') was presented to the audience in the conference hall of Sh. Marjani Institute of History, Tatarstan Academy of Sciences. The presentation was timed to coincide with the publication of the last two volumes of this year series: *The History of the Tartars. Volume IV: The*

*Tatar States of the 15th-18th Centuries* and *The History of the Tartars. Volume V: The Tatar People in the Russian State (the second half of the 16th and 18th centuries)*.

This seven-volume edition of *The History of the Tatars since Ancient Times* has been elaborated for more than 10 years under the auspices of Sh. Marjani Institute of History, Tatarstan Academy of Sciences, and its scientific and methodological guidance. More than two hundred prominent scholars from the Institute and other leading scientific centers of the neighboring countries and beyond took part in its creation. Each volume covers a fundamentally new period in the history of the Tatars. In 2002, the first volume of *The History of the Tatars since Ancient Times* was published, it was dedicated to the peoples of the Eurasian steppe living in ancient times. In 2006, the second volume of *The History of the Tartars. Volume II: Volga Bulgaria and the Great Steppe* and, in 2009, the third volume of *The History of the Tartars. Volume III: Jochi Ulus* were released. In 2013, two volumes appeared: the sixth volume was dedicated to the formation of the Tatar nation in the 19th and the early 20th centuries, and the seventh one was written on the history of the Tatar people and Tatarstan in the 20th and early 21st centuries.

The ceremony was attended by R.S.Khakimov, Doctor of History, Director of Sh. Marjani Institute of History, Tatarstan Academy of Sciences, Pr. F.S.Sibagatullin, a deputy of the State Duma, the Federal Assembly of the Russian Federation, N.M.Valeev, Doctor of Philology, an academician and secretary of the Humanities Department of Tatarstan Academy of Sciences, authors and editors of this scientific publication as well as representatives of the Kazan academic community.

At the opening session, Director of Sh.Marjani Institute of History R.Khakimov summed up the entire work on the seven-volume edition, focusing on the specific difficulties and challenges associated with the distortion of the history of the Tatars in the official historiography. He expressed hope that the academic work “The History of the Tartars” will help to explain and reinterpret certain historical events.

The speakers at the presentation called that day historic and remarkable. The release of the seven-volume academic edition *The History of the Tatars since Ancient Times* has become a big event in the sphere of the Humanities, which enables us to take a new look at all the stages of the historical development of the Tatars and the Turkic world from ancient times to the beginning of the 21st century.

---

On the occasion of the 170th anniversary of the great poet and philosopher Abai, Kazakhstan held various scientific, cultural and educational events. Professor Hatip Minnegulov, Kazan Federal University, participated in a few of them. Namely, on August 6, 2015, the professor from Kazan presented his report “Abai and Tatar Literature” to the plenary audience at the International Scientific-Practical Conference, which took place in Semipalatinsk, the native city of the poet. The conference was hosted by the State University named after Shakarim. Besides, H.M.Minnegulov spoke at a gala evening at the Bolshoi Theater named after Abai, as well as on several Kazakhstan TV channels.

On October 30, the most prestigious university in Kazakhstan, Nazarbayev University (Astana), hosted the International Scientific and Practical Conference “Abai, the Phenomenon of the World”, where H.Minnegulov spoke on “Abai and Tukay,” he also gave several interviews to Kazakhstan television and radio. The professor of Kazan Federal University met with representatives of the Tatar community in Astana at the office of the Research and Education Center “Kayum Nasyri Institute”, the Eurasian National University named after L.N.Gumilev, and told his expatriates about Tatar literature, culture, history, and relationships between Kazakh and Tatar literature. The meeting was attended by Rustem Valiullov, the plenipotentiary of the Republic of Tatarstan in Kazakhstan, Kamil Mullashev, People’s Artist of the Republic of Tatarstan and other prominent people.

---

On December 12, 2015, Bashkir State Pedagogical University named after Miftakhetdin Akmulla hosted the presentation of the “Etymological Dictionary of the Tatar Language.” The event was attended by scientists and students from different universities, members of public organizations of the Republic of Bashkortostan, as well as the guests – the author of the dictionary, Doctor of Philology, Professor Rifkat Akhmet’yanov and researchers from G.Ibragimov Institute of Language, Literature and Art of the Tatar-

stan Academy of Sciences. Everyone highly appreciated this unique scientific publication, pointed out its importance for lexicology and expressed their gratitude to the compliers of the dictionary and the “Berlek” organization.

*This information was submitted by H.Yu.Minnegulov, Doctor of Philology, Professor in the Institute of Philology and Intercultural Communication named after Leo Tolstoy, Kazan Federal University; D.Sh.Suleymanov, Academician of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Director of the Research Institute of "Applied Semiotics" at the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Doctor of Technical Sciences, Professor of Kazan University; G.R.Galiullina, Doctor of Philology, Professor in the Institute of Philology and Intercultural Communication named after Leo Tolstoy, Kazan Federal University; F.Sh.Nurieva, Doctor of Philology, Professor in the Institute of Philology and Intercultural Communication named after Leo Tolstoy, Kazan Federal University; M.M.Gibatdinov, Ph.D. in Pedagogy, Head of the Center for the History and Theory of National Education at the Institute of History named after Sh.Mardzhani, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan; G.F.Shayhieva, Head of the Information-Analytical Department of the World Congress of Tatars; E.A.Gorobets, Ph.D. in Philology, Associate Professor in the Institute of Philology and Intercultural Communication named after Leo Tolstoy, Kazan Federal University; Z.N.Kirillova, Ph.D. in Philology, Associate Professor in the Institute of Philology and Intercultural Communication named after Leo Tolstoy, Kazan Federal University; E.N.Dinmuhametova, Ph.D. in Philology, Associate Professor in the Institute of Philology and Intercultural Communication named after Leo Tolstoy, Kazan Federal University.*

# 2015 ЕЛДА БУЛГАН ВАКЫЙГАЛАР

2015 елның 17-19 сентябрендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә һәм Казан федераль университетында төрки телләрне компьютерда эшкәртү технологияләре буенча «TurkLang 2015» исемле III Халыкара фәнни конференция үтте.

Конференциянең традицион эш юнәлешләре төрки телләр өчен формаль калыплардан гыйбарәт иде: компьютер системаларының милли локализациясе һәм терминология, төрки телләрнең электрон корпусы, текстларны морфологик һәм синтаксик эшкәртү системалары, сөйләмне тану һәм синтезлау системасы, текстны семантик эшкәртү системасы, машина тәрҗемәсе системасы, төрки телләрне өйрәнүдә интеллектуаль системалар һәм технологияләр, төрки телләрдә лингвистик онтологияләр.

Конференциядә чыгыш ясаучылар төрки телләрне компьютерда эшкәртү өлкәсендәге фәнара бәйләнешләрнең актуальлеген һәм мондый юнәлештәге эшчәнлекнең әһәмиятен билгеләп уздылар.

18-19 сентябрьдә конференция үзенең эшен Казан федераль университетының Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында дәвам итте. Пленар һәм секцион докладлардан тыш төрле мастер-дәресләр һәм түгәрәк өстәлләр, программа прдукцияләрен күрсәтү, чит ил докладчылары катнашында виртуаль чыгышлар булды.

Конференция эшендә, академик мәктәп вәкилләре белән берлектә, бизнес-оешмалар хезмәткәрләре катнашты, аерым алганда, Яндекс компаниясе вәкилләре татарча-русча машина тәрҗемәсе системасы турында чыгыш ясадылар.

Конференциядә катнашучылар, уңышлы чишелеше лингвистик эзләнүләрнең нәтиҗәләре белән тел мәгълүматларын эшкәртүнең заманча компьютер методларын берләштерүне таләп иткән күпкырлы проблемалар һәм бурычларны хәл итү өчен, хезмәттәшлекне киңәйтү һәм көчләрне берләштерү турында килештеләр.

---

2015 елның 2 октябрендә Мәскәү университетының Азия һәм Африка илләре институтында әлеге уку йортының төрки филология кафедрасы мөдире филология фәннәре докторы профессор Дмитрий Михайлович Насиловның юбилее хөрмәтенә «Дмитриев укулары» дип исемләнгән 23 Халыкара тюркологик конференция булып узды. Галимнең төрки һәм алтай тел гыйлеме буенча язылган фәнни хезмәтләре (тюркология тарихы, төрки телләрнең чагыштырма-тарихи, тасвирлама һәм теоретик грамматикасы, алтай тел гыйлеме һ.б. буенча эзләнүләре) илебездә генә түгел, чит илләрдә дә киң танылган. Аның гыйльми мәктәбендә Россия һәм чит ил тюрколог, алтаист галимнәре тәрбияләнгән. Дмитрий Михайлович, институтта кафедра мөдирлеге һәм укыту вазифаларыннан тыш, киң җәмәгать эшчәнлеге дә алып бара: РФАнең тарих-филология фәннәре бүлеге каршында Тюркологларның Россия комитеты рәисе урынбасары, «Россия тюркологиясе» («Российская тюркология») журналының баш мөхәррире, РФ Дәүләт думасының Милләтләр эшләре комитеты каршындагы РФнең аз санлы халыкларының нигез телләре мәсьәләләре буенча эксперт төркем әгъзасы, РГНФ эксперты, Төрек лингвистик җәмгыятенең мактаулы әгъзасы (Türk Dili Kurumu) һ.б.

Конференциянең ике тематик секциясендә Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан, Кызыл, Элиста, Киев, Әнкара һ.б. шәһәрләрнең университет һәм тикшеренү институтларыннан галимнәр җәмгысе 34 доклад тәкъдим итте. Төрки дөньяда фәнни багланышларны ныгытуга һәм Мәскәү тюркологик мәктәбенең традицияләрен саклауга юнәлтелгән әлеге чараны оештыруда МДУның Азия һәм Африка илләре институты төрки филология кафедрасы башлап йөрде.

---

2015 елның 12-15 октябрендә КФУның Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында дөньякүләм танылган Казан лингвистик мәктәбенә нигез салучы һәм аның җитәкчесе, галим, Фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты, Казан университетының

мактаулы профессоры Иван Александрович Бодуэн де Куртенэның (1845-1929) тууына 170 ел һәм Казан университетында эшли башлавына 140 ел тулуга багышланган «И.А.Бодуэн де Куртенэ һәм дөньякүләм лингвистика» Халыкара конференциясе булып узды.

Конференция эшендә Австрия, Алмания, Польша, Төркия, Чехия, БДБ илләреннән һәм Россиянең төрле шәһәрләреннән галимнәр катнашты.

Пленар утырышта кунакларны һәм конференциядә катнашучыларны КФУның фәнни эшчәнлек буенча проректоры геология-минералогия фәннәре докторы профессор Д.К.Нургалиев, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министры урынбасары И.Р.Мөхәммәтов, Россия Фәннәр академиясенең Тел белеме институты директоры филология фәннәре докторы профессор В.М.Алпатов, Польша Республикасының Россия Федерациясендәге илчесе урынбасары М.Чесьлик сәламләделәр.

Конференцияне оештыруда Россия Фәннәр академиясенең Лингвистик тикшеренүләр институты, Россия Фәннәр академиясенең Рус теле институты, Россия Фәннәр академиясенең Тел белеме институты, «Көнчыгыш Европа» Гиссен үзәге, Польша Республикасының Россия Федерациясендәге Вәкиллеге катнашты.

Халыкара конференция - башлангычында яки фәнни нигезләүдә И.А.Бодуэн де Куртенэ һәм Казан лингвистик мәктәбенең башка вәкилләре катнашкан хәзерге нәзари һәм гамәли тел белеме юнәлешләренең күптөрле мәсьәләләренә багышланган иде.

Хәзерге вакытта Казан лингвистика мәктәбе идеяләре Казан университетының тел галимнәре тарафыннан тормышка ашырыла. Шунысын аерым билгеләп үтәргә кирәк: Казан лингвистика мәктәбенең башлангыч идеяләре гасыр ярым дәвамында юкка чыкмады, аның үсеш юнәлешләре һәрвакыт заманның фәнни таләпләренә җавап бирде дип әйтергә мөмкин. Бу турыда Россия һәм чит илләрнең әйдәп баручы галимнәре РФАнең Тел белеме институты директоры филология фәннәре докторы профессор В.М.Алпатов; Мәскәү дәүләт университетының нейропсихология лабораториясе мөдире психология фәннәре докторы профессор Т.В.Ахутина; Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры филология фәннәре докторы профессор Р.Р.Җамалетдинов; РФАнең Лингвистик тикшеренүләр институты директор урынбасары филология фәннәре докторы профессор Е.В.Головко; Ольштындагы Варминск-Мазурск университеты профессоры филология фәннәре докторы А.Киклевич, Вена университеты профессоры филология фәннәре докторы Х.Микласның пленар утырышта ясаган докладларында билгеләп үтелде.

Секция утырышларында хәзерге фәндә Казан лингвистика мәктәбе идеяләрен үстерүнең актуаль сораулары: гамәли лингвистика өлкәсендә – компьютер лингвистикасы, нейролингвистика, психолингвистика; когнитив лингвистика тармагындагы уңышлар, фонетика, фонология, морфемика, сүз ясалышы, грамматика, текст һәм дискурс, семантика мәсьәләләре күтәрелде.

Конференция РФ һәм ТРның Мәгариф һәм фән министрлыгы, ТРның Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасының «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы ярдәме белән үткәрелде.

---

2015 елның 14 октябрендә Казан федераль университетында «Телләрне һәм мәдәниятләрне үстерү һәм саклау»дигән IV Халыкара форум ачылды.

Форум эшендә Россия, якын һәм ерак чит илләрдән – АКШ, Алмания, Англия, Австрия, Төркия, Украина, Иран, Әрмәнстан, Казахстан, Үзбәкстан һәм башка илләрдән – 500дән артык галим катнашты.

Телләрне һәм мәдәниятләрне саклау мәсьәләсе бөтен кешелек җәмгыятен борчый. ЮНЕСКО мәгълүматларына караганда, бүгенге көндә 6,5 мең телнең яртысына юкка чыгу куркынычы яный. Белгечләр фикеренчә, балаларның өчтән бере үз туган телен өйрәнмәсә, ул халык юкка чыгарга мөмкин.

Форум Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, ТРның Мәгариф һәм фән министрлыгы, ТРның Фәннәр академиясе, Татар федераль милли-мәдәни автономиясе, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы югары уку йортлары ректорлары советы каршындагы күпмәдәниятле белем бирүне үстерү буенча вузара советы, Мәскәү дәүләт университеты базасында педагогик кадрларны әзерләү өлкәсендә укыту методик берләшмәсенең «Туган (татар) теле һәм мәдәнияте» белгечлеге буенча Укыту-методик комиссиясе, М.В.Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университеты базасында классик университет белеме бирү буенча Укыту-методик берләшмәсенең Филология советы ярдәме белән, Казан федераль университеты тарафыннан әзерләнде.

Форумның тантаналы ачылышында КФУның белем бирү эшчәнлеге буенча проректоры Д.А.Таюрский, Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Р.Р.Җамалетдинов; Татарстан Республикасы Президентының эчке сәясәт мәсьәләләре департаментының милли сәясәтне гамәлгә ашыру идарәсе башлыгы Д.М.Мостафин, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү бүлеге мөдире Г.Гыйльманов, Төркия Республикасының Казандагы генераль консулы һ.б. катнаштылар.

Форум кысаларында түбәндәге чаралар үткәрелде:

«Күп мәдәниятле һәм күп конфессияле җәмгыятьтә туган телләрне һәм мәдәниятләрне саклау һәм үстерү: дөнья тәҗрибәсе һәм заманча технологияләр» дип аталган Халыкара фәнни-гамәли конференция;

«Бүгенге көн германистикасы» дигән Халыкара фәнни конференция;

«Шәрык һәм Гареб мәдәниятләре контекстында төрки халыклар әдәбияты һәм сәнгате» дип аталган Халыкара фәнни-гамәли конференция;

«Чагыштырма лингвистиканың гамәли аспектлары: туган тел нигезендә чит телгә өйрәтү» дип аталган II Халыкара фәнни-гамәли конференция;

Татар теле укытучыларының «Техник һәм табигый фәннәр факультетларында татар телен укытуда заманча методларны куллану» республикакүләм вузара фәнни-методик семинары;

Укучылар һәм студентларның «Мәһдиев укулары» Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе;

«Мәдәниятара багланышлар контекстында сәнгать һәм сәнгати белем» IV Халыкара фәнни-гамәли конференциясе;

Рус телле студентлар өчен татар теленнән VIII Республика вузара студентлар олимпиадасы.

---

2015 елның 15-17 октябрендә Казан федераль (Идел буе) университетының Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәнияте бүлеге укытучылары Э.Х.Кадыйрова һәм З.Н.Кириллова Төркиянең Чанаккалә шәһәре 18 нче март исемендәге университетта узган «YIII Төрек дөнья теле» («VIII Dünya Dili Türkçe») халыкара тюркология симпозиумында катнаштылар.

Төрки телләргә багышланган әлеге симпозиумга дөньяның күп илләреннән галимнәр җыелган иде. Төркиянең төрле шәһәрләреннән, Россия, Азәрбайҗан, Казахстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Украина, Болгария, Македония, Албания, Босния һәм Герцеговина, Әфганстан кебек дәүләт һәм республикалардан да делегацияләр яки аерым галимнәр катнашты. Татарстаннан исә, КФУ галимнәреннән тыш, күренекле диалектолог Ф.Юсупов һәм фольклорчы Л.Дәүләтшина да бар иде.

Татар тел белеме кафедрасы доценты Энҗе Кадыйрова Казан университетының Н.И.Лобачевский исемендәге китапханәсендә саклана торган «Гарәпчә-төркичә сүзлек» (1581) хакында сөйләде, аның лексикасындагы төп тематик катламнар, сүзләрнең бирелү үзенчәлекләре, сүзлекнең аерым битләреннән фотокопияләр белән таныштырды. Гомуми һәм төрки тел белеме кафедрасы доценты Зоя Кириллова исә керәшен татарлары сөйләшләрендәге татар әдәби теленең тарихи сүзләр һәм архаизмнар катламын тәшкил иткән төрки нигезле сүзләр һәм алынмалар турында чыгыш ясады, күп санлы мисаллар, фотолар, чуваш һәм удмуртлар белән уртак кием үрнәкләре белән дә таныштырды. Чыгышлар симпозиум кунакларында зур кызыксыну тудырды, сораулар бирелде һәм фикер алышулар булды.

«Dünya Dili Türkçe» халыкара симпозиумы Төркиянең төрле шәһәрләрендә үткәрелә. Чанаккалә каласы сайлануның да тарихи сәбәбе бар. 100 ел элек бу шәһәрдә Беренче Бөтендөнья сугышының Төркия дәүләте өчен хәлиткеч бәрелеше була. Антанта илләре Дарданелла бугазын җиңел генә басып алырга теләсәләр дә, төрек гаскәре канкойгыч сугышлар нәтиҗәсендә зур җиңүгә ирешә, күп корбаннар исәбенә үз җирләрен саклап кала. Быелгы симпозиумны кабул иткән университет та шул вакыйгалар истәлегенә 18 нче март исемен йөртә.

Кардәш халыкларны берләштерү максатын куеп, төрки телләрнең үзенчәлекләрен, уртак тарихи катламнарын барлау белән шөгыльләнгән тюркология симпозиумы быел да үзенең максатына иреште. Тугандаш төрек халкының зур горурлыгы булган, Эгей һәм Мәрмәр диңгезләрен тоташтыручы атаклы Дарданелла бугазы ярында урнашкан Чанаккалә шәһәре искиткеч матур табигате, ачык йөзле, кунакчыл кешеләре белән дә симпозиум кунакларының хәтерендә сакланыр.

---

2015 елның 16-18 октябрендә Франциянең Париж шәһәрендә «Европа татарлары альянсы»ның Икенче съезды узды. Корылтайның эш урыны Франциядәге Россия вәкиллегендә булды.

Анда Россия Федерациясенең Франциядәге Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле илчесе Александр Орлов, Франциядә Россия белән хезмәттәшлек итү вәкиле, Россиянең Париждагы фән һәм мәдәният үзәге директоры Игорь Шпынов, РФ Тышкы эшләр министрлыгының Чит илләрдәге ватандашлар белән эшләү Департаменты директоры урынбасары Константин Климовский һәм башкалар катнашты.

